РАСЛЫЙМ
«Сәләт» ТРЯИФ
Генераль директоры
_______________ Җ.Ш. Сөләйманов
30 март, 2021 ел

**Әдип Әлмир кубогына VII шахмат турниры үткәрү турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Шахмат турниры оештыручылары (алга таба – Турнир) – Татарстан Республикасының «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды (алга таба – «Сәләт» ТРЯИФ), «Сәләт» яшьләр үзәге дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба - «Сәләт» ЯҮ ДБУ), Сәләт клубы (алга таба – Клуб). Турнир Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә оештырыла.

1.2. Турнирны үткәргәндә, оештыру комитеты Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары, Россия Федерациясе министрлыкларының һәм ведомстволарының норматив-хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

**2. Максат һәм бурычлар**

2.1. Максат:

- Сәләт мохитендә шахмат уенын популярлаштыру, шахмат уйнауны активлаштыру, яшьләр арасында бу уенга кызыксыну уяту.

2.2. Бурычлар:

- яшьләр арасында шахмат казанышларын пропагандалау, шахмат уйнауны яшьләр арасында гадәткә кертү, шахмат уеннарына, шахмат турнирларына җәлеп итү;
- актив һәм сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм туплау.

**3.Турнирны оештыру**

3.1. Турнирны оештыру өчен клуб активистлары арасыннан оештыру комитеты төзелә.

3.2. Оештыру Комитетының бурычлары:

- турнирны үткәрү формасын билгеләү, аның эчтәлеген эшләү һәм өстәмә материаллар әзерләү;
- турнирны үткәрү методикасын эшләү, кирәкле форма һәм бланклар, кирәкле техник документлар әзерләү (мәгълүмати хатлар, турлар бланклары, катнашучылар өчен грамоталар һ. б.);
- катнашучыларга массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирүне оештыру, катнашу өчен гаризалар кабул итү, турнирны уздыру мәсьәләләре буенча элемтәдә тору;
- казыйлар командасын оештыру;
- турнирга йомгак ясау, аның нәтиҗәләрен билгеләү.

**4. Турнирны үткәрү вакыты һәм урыны**

4.1. Турнир 2 этаптан гыйбарәт: онлайн һәм офлайн.

4.1.1. Онлайн этабы 2021 елның 27-нче апрелендә lichess.org платформасы кулланып үткәрелә. Аның нәтиҗәләре буенча иң шәп 50 уенчы билгеләнә – алар офлайн этабына уза.

4.1.2. Офлайн этабы 2021 елның 5-нче маенда Сәләт Йортында (Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт) үткәрелә.

9.30 – катнашучыларны теркәү, 10:30 – турнир башлана.

**5. Казыйлар коллегиясе**

5.1. Турнирны үткәрү өчен казыйлар коллегиясе төзелә. Оештыру тәртибе, казыйлар коллегиясе составы, аның эш регламенты турнирның Оештыру комитеты тарафыннан раслана.

5.2. Турнирның казыйлар коллегиясе:
- турнир кысаларында кагыйдәләр исемлеген раслый;
- турнирны әзерләү һәм үткәрү буенча Оештыру комитетына тәкъдимнәр кертә;
- төп һәм махсус номинацияләрдә җиңүчеләр турында карар кабул итә;
- турнир нәтиҗәләре һәм җиңүчеләр исемлеген раслау өчен оештыру комитетына бирә.

5.3. Турнирның баш казые:
- турнир казыйларына, анда катнашучыларга һәм кунакларга уеннарны уздыру тәртибе хакында консультацияләр бирә, шулай ук турнир барышында казыйлары эше белән җитәкчелек итә, бәхәсле ситуацияләрне хәл итә.

**6. Турнирда катнашучылар**

6.1. Турнирда катнашу өчен 7 яшьтән 17 яшькә кадәр булган мәктәп укучылары чакырыла.

6.2. Турнирның үткәрелү шарты - кимендә 4 уенчы катнашу.

**7. Турнирны үткәрү кагыйдәләре**

7.1.Турнир ФИДА шахмат уеннары кагыйдәләре буенча үткәрелә.
7.2. Ярышлар өч төркемдә үткәрелә:
– I төркем – һәвәскәр уенчылар (разрядсыз);
– II төркем – разряды булган уенчылар (1-3 разрядлы);
7.3. Ярышлар «Швейцария системасы» буенча үткәрелә.
7.4. Вакыт контроле: партия азагына кадәр һәр катнашучы өчен 10 минут бирелә. Кирәк булган очракта баш казыйлар коллегиясе турнир регламентына үзгәрешләр кертергә хокуклы.

**8. Финанслау**

8.1. Турнир оештыруны «Сәләт» ТРЯИФ финанслый.

**9. Гаризалар бирү тәртибе һәм вакыты**

9.1. Турнирда катнашу өчен гариза үрнәктә күрсәтелгәнчә (Кушымта) тутырылып, оештыру комитеты адресына җибәрелә: timerhan@selet.biz, яисә Сәләт оешмасының рәсми сайтында тутырыла: www.selet.biz. Шулай ук, lichess.org сайтында теркәлү кирәк.
9.2. Турнир башлануга кадәр 3 көн кала гаризалар кабул итү туктатыла.
9.3. Мәгълүмат алу өчен телефон: 7-909-312-62-44 – Эльвира Илгизовна Мөхәммәтҗанова.

Кушымта

Әдип Әлмир кубогына шахмат турнирында катнашу өчен

**ГАРИЗА**

| № | Уенчының фамилиясе, исеме, этисенең исеме (тулысынча) | Туган көне (көн/ай/ел) | Элемтә өчен телефон | Разряды, дәрәҗәсе | lichess.org сайтында теркәлгән никнеймы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |